КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 26 май г.Казань № 310

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясеннән даими яшәргә читкә күчеп китүче (киткән) затларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә тиешле елларны эшләгән өчен пенсияләр һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләүләр түләү тәртибе турында» 2006 ел, 13 гыйнвар, 2 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 март, 209 нчы, 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясеннән даими яшәргә читкә күчеп китүче (киткән) затларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә тиешле елларны эшләгән өчен пенсияләр һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләүләр түләү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктта «кредит учреждениеләрендә» сүзләрен «кредит оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пукнтның беренче абзацында «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон белән» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктта «кредит учреждениеләрендә» сүзләрен «кредит оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче, 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәләләр).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 9 июнь, 290 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 13

декабрь, 1013 нче, 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның өченче абзацында «алга таба – дәүләт хезмәте» сүзләрен «алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфалары» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия фондының яшәү урыны буенча территориаль органы бирә торган картлык буенча иминият пенсиясен вакытыннан алда яки инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләүгә документлары белән гаризаны кабул итү турында хәбәрнамә күчермәсе – «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеш нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәнче пенсия билгеләгәндә;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Граждан пенсиягә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә) өстәмә түләүгә хокук барлыкка килгәннән һәм «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеш нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң, яисә картлык буенча иминият пенсиясен вакытыннан алда яки инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләгәннән соң теләсә кайсы вакытта мөрәҗәгать итә ала.»;

3.1 пунктта:

өченче абзацта «(дәүләт хезмәте вазыйфаларын 1997 елның 1 гыйнварыннан соң биләгән затлар өчен)» сүзләрен «(дәүләт хезмәте вазыйфаларын 1997 елның 1 гыйнварыннан алып 2015 елның 31 декабренә кадәр чорда биләгән затлар өчен)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасыннан 2016 елның 1 гыйнварыннан дәүләт хезмәткәрләре били торган вазыйфалар реестрына дәүләт хезмәткәрен кертү турында мәгълүматлар ала.»;

4.5 пунктта «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункт нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң, яисә картлык буенча хезмәт пенсиясен (хезмәт пенсиясе өлешен) вакытыннан алда яки инвалидлык буенча хезмәт пенсиясен билгеләгәннән соң» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеш нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң, яисә картлык буенча иминият пенсиясен вакытыннан алда яки инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләгәннән соң» сүзләренә алмаштырырга»;

4.9 пунктта «хезмәт пенсиясеннән» сүзләрен «иминият пенсиясенннән» сүзләренә алмаштырырга»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Пенсиягә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә) өстәмә түләүне түләү федераль дәүләт граждан хезмәткәре яки муниципаль хезмәткәр пенсиясе, башка нигезләр буенча тиешле еллар эшләгән өчен пенсия, айлык гомерлек түләү, Татарстан Республиксында муниципаль вазыйфаларны биләгән затлар пенсияләренә айлык өстәмә түләү, өстәмә (гомер буе) айлык матди тәэмин итү, инвалидлык бунча пенсия (инвалидлык буенча иминият пенсиясеннән тыш), федераль законнар, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең бүтән субъектлары законнары, җирле үзидарә органнары актлары нигезендә федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, Россия Федерациясенең бүтән субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан картлык (инвалидлык) буенча пенсиягә бүтән айлык өстәмә түләүләр түләү.»;

6.1 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлеш нигезендә билгеләнгән картлык буенча иминият пенсиясенә теркәлгән түләү зурлыгын үзгәртү;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\310.docx